**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№501**
**06.02.2020**

Муниципаль милектәге җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Муниципаль милектәге җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Муниципаль милектәге җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 21 сентябрендәге 5617 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2020 елның 6 февралендәге
501 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль милектәге җир участогын
аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага
бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - Регламент) муниципаль милектәге җир участогын Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы: Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе (алга таба - ҖММИ).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

ҖММИнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 233 кабинет.

Башкарма комитетның эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр, шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

ҖММИнең белешмә телефоны: 30-55-54.

Башкарма комитет бинасына керү шәхесне раслаучы документ буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы (http:// www.nabchelny.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында, шулай ук Башкарма комитетның урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат түбәндәге юл белән алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайты (http://www.nabchelny.ru) аша;

3) «Интернет» челтәрендә сатуларны үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясе рәсми сайты аша (http://torgi.gov.ru) (алга таба – Россия Федерациясенең рәсми сайты);

4) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

5) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http:// www.gosuslugi.ru);

6) Башкарма комитетта (ҖММИ):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта (uzioIP@yandex.ru) аша электрон рәвештә.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат ҖММИ белгече тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясенең 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Граждан кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 05.12.1994, № 32, ст. 3301) (алга таба – РФ Граждан кодексы);

2) Россия Федерациясенең 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Җир кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2001, № 44, ст. 4147) (алга таба – РФ Җир кодексы);

3) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 06.10.2003, № 40, ст. 3822);

4) «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 03.08.1998, № 31, ст. 3813);

5) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179) (алга таба – 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

6) «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 20.07.2015, № 29 (I бүлек), ст. 4344 (алга таба – 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон);

7) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт яки муниципаль милектә булган җир участокларын арендалау вакытында аренда түләвен билгеләүнең төп принциплары һәм аренда түләве күләмен билгеләү кагыйдәләре турында, шулай ук Россия Федерациясе милкендәге җирләр өчен аренда түләве кертү тәртибен, шартларын һәм срокларын билгеләү турында» 2009 елның 16 июлендәге 582 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2009 елның 16 июлендәге 582 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.07.2009, № 30, ст. 3821);

8) Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының урнашу схемасын әзерләүгә һәм территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының урнашу схемасын электрон документ формасында әзерләгәндә, территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының урнашу схемасы форматына таләпләрне, кәгазь документ формасында әзерләү гамәлгә ашырыла торган, территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының урнашу схемасы формасын раслау турында» 2014 елның 27 ноябрендәге 762 номерлы приказы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2014 елның 27 ноябрендәге 762 номерлы приказы) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 18.02.2015);

9) Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәреннән файдаланып, электрон документлар рәвешендә территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының урнашу схемасын раслау турында гаризалар, дәүләт һәм муниципаль милектәгеге җир участогын сату буенча аукцион яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын арендалау килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү турында гариза, дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын бирүне алдан килештерү турында гариза, дәүләт яки муниципаль милектәге

җир участогын бирү турында гариза һәм дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир участокларын һәм шәхси милектәге җир участокларын яңадан бүлү турында гариза бирү тәртибен һәм ысулларын, шулай ук аларның форматына карата таләпләрне раслау турында» 2015 елның 14 гыйнварындагы 7 номерлы приказы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2015 елның 14 гыйнварындагы 7 номерлы приказы) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 18.02.2015);

10) Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Законы (Республика Татарстан, № 155-156, 03.08.2004) (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы);

11) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Шәһәр Уставы) (Челнинские известия, 10.12.2005 № 235-237 30.12.2005 № 249);

12) Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге (алга таба – Муниципаль хезмәтләр исемлеге);

13) Башкарма комитетның «Территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 22 июлендәге 3738 номерлы карары (алга таба – җир участогының урнашу схемасын раслау буенча административ регламент);

14) Башкарма комитетның 2017 елның 28 декабрендәге 1210-р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турында нигезләмә (алга таба – ҖММИ турында нигезләмә);

15) Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

16) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2007 елның 16 июлендәге 754 номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре).

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр файдаланыла:

аукционны оештыручы – вәкаләтле орган яки вәкаләтле орган белән килешү нигезендә эш итүче махсуслаштырылган оешма;

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) ул – ул муниципаль хезмәт күүрсәтү турында запрос (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 пункт). Гаризалар, Регламентның 1 нче, 2 нче кушымталары нигезендә, стандарт бланкта тутырыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Муниципаль милектәге җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү | РФ Җир кодексының 39.6 статьясындагы 1 пункт |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә органының исеме | ҖММИ исеменнән Башкарма комитет | РФ Җир кодексының 39.2 статьясы;<br>2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>шәһәр Уставының 41статьясы<br>ҖММИ турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | 1) аукцион үткәрү турында карар яки муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хат;<br>2) җир участогын арендалау килешүе һәм җир участогын кабул итү-тапшыру акты | РФ Җир кодексының 39.1статьясындагы 1 пункт, 39.11 статьясындагы 4 пунктның 9 пунктчасы, 39.18 статьясындагы 5 пункт;<br>ҖММИ турында нигезләмә |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итүне исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктату мөмкинлеге каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату срогы | Аукцион үткәрү турында карар яисә муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар кабул итү - гариза кергән көннән башлап ике айдан артмаган срокта.<br>Аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәне Россия Федерациясенең рәсми сайтында урнаштыру - әлеге беркетмә имзаланган көннән башлап бер эш көне эчендә.<br>Өч нөсхәдә җир участогын арендалау килешүенең имзаланган проектын бирү - беркетмә төзелгән көннән башлап ун календарь көн эчендә.<br>Бәяләү оешмасы һәм аукционны оештыручы махсуслаштырылган оешма белән муниципаль контрактлар төзүгә һәм аукционны үткәрүгә бәйле көтү срогы муниципаль хезмәт күрсәтү срогына керми . | РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктның 9 пунктчасы, 39.12 статьясындагы 16, 20 пунктлар, 39.18 статьясы |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1) гариза (1 нче кушымта), җир участогын булдырырга кирәк булган очракта;<br>2) гариза (2 нче кушымта), җир участогы булдырылган очракта;<br>3) гариза бирүченең яисә гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклаучы документ күчермәсе, гариза ТР Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша җибәрелгән очрактан тыш;<br>4) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, гаризаны гариза бирүченең вәкиле биргән очракта;<br>5) җир участогының урнашу схемасы, әгәр җир участогын булдырырга кирәк булса һәм аның чикләрендә җир участогын булдыру | РФ Җир кодексының 39.11статьясындагы 4, 5 пунктлар;<br>Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2015 елның 14 гыйнварындагы 7 номерлы приказы;<br>ҖММИ турында нигезләмә |

| | | |
|---|---|---|
| | күздә тотылган территорияне межалау проекты расланмаган булса;<br>6) аукционны үткәрү турындагы хәбәрдә билгеләнгән формада аукционда катнашуга заявка, задатокны кире кайтару өчен исәп-хисап счетының банк реквизитларын күрсәтеп;<br>7) задаток кертүне раслаучы документлар.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән кәгазьдә җибәрелергә мөмкин:<br>шәхсән (ышаныч язуы нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);<br>тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат белән почта аша.<br>Гаризалар һәм документлар шулай ук электрон имза яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, «Интернет» челтәре аша, шул исәптән ТР Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша тапшырылырга мөмкин. | |
| 2.6. Муниципаль хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | 1) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә (гариза бирүче булып юридик зат торган очракта);<br>2) Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә (гариза бирүче булып шәхси эшмәкәр торган очракта);<br>3) күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (сорала торган җир участогына карата);<br>4) күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (сорала торган җир участогында урнашкан объектка (объектларга) карата);<br>5) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан күчемсез милек объекты турында өземтә;<br>6) инженерлык челтәрләренә һәм коммуникацияләренә тоташтыруның техник шартлары. | 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы, 7.1 статьясы;<br>2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килештерү (муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла) таләп ителә торган җирле үзидарә органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | 1) Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе;<br>2) Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе;<br>3) Башкарма комитетның хокук идарәсе;<br>4) Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе. | Эш регламенты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Документлар тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылу;<br>2) тапшырылган документлар Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү;<br>3) гаризада һәм аңа теркәлгән документларда алдан килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлегенә төшенергә мөмкинлек бирми торган җитди бозулар булу;<br>4) документлар тиешле булмаган органга бирелү. | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр:<br>Башкарма комитетка җир участогының урнашу схемасын раслау турында гариза кергән вакытка Башкарма комитет каравында башка зат тарафыннан элегрәк тәкъдим ителгән җир участогының урнашу схемасы һәм бу схемалар белән каралган җир участокларының урнашу урыны өлешчә яки тулысынча туры килгән очракта.<br>Җир участогының урнашу схемасын раслау турында соңрак бирелгән гаризаны карап тикшерү элек җибәрелгән җир участогы урнашу схемасын раслау турында карар кабул ителгәнчегә кадәр яисә элек җибәрелгән җир участогы урнашу схемасын раслаудан баш тарту турында карар кабул ителгәнчегә кадәр туктатыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җир участогы чикләренә 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә төгәллек кертелергә тиеш;<br>2) җир участогына дәүләт яки муниципаль милек хокукы теркәлмәгән (мондый җир участогы дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән яисә җир участокларыннан барлыкка килгән очраклардан тыш);<br>3) җир участогына карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкциянең чик параметрлары билгеләнмәгән (җир участогын рөхсәт ителгән файдалану нигезендә биналар, корылмалар төзү мөмкинлеге каралмаган очраклардан тыш);<br>4) җир участогына карата объектларны инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) буенча техник шартлар турында мәгълүматлар булмау (җир участогын рөхсәт ителгән файдалану нигезендә биналар, корылмалар төзү мөмкинлеге каралмаган һәм территорияне комплекслы үзләштерү өчен җир участогын арендалау килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү очракларыннан тыш);<br>5) җир участогына карата җир участогын рөхсәт ителгән файдалану билгеләнмәгән яки җир участогын рөхсәт ителгән файдалану аукцион үткәрү турында гаризада күрсәтелгән җир участогыннан файдалану максатларына туры килми;<br>6) җир участогы тулысынча территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чикләрендә урнашкан, андагы җир | РФ Җир кодексның<br>39.11 статьясындагы 4 пунктның 3 пунктчасы, 8 пункты;<br>РФ Җир кодексының<br>39.12 статьясындагы 8 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | участокларыннан файдалануга билгеләнгән чикләүләр аукцион үткәрү турында гаризада күрсәтелгән җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә мондый җир участогыннан файдалануны рөхсәт итми;<br>7) җир участогы билгеле бер җир категориясенә кертелмәгән;<br>8) җир участогы даими (сроксыз) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мирас итеп алу яки аренда хокукында бирелгән;<br>9) җир участогында гражданнар яисә юридик затлар карамагындагы бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект урнашкан (җир участогында аларны урнаштыру сервитут, ачык сервитут нигезендә рөхсәт ителгән корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки РФ Җир кодексының 39.36 статьясы нигезендә урнаштырылган объектлар урнашкан очраклардан тыш, шулай ук җир участогын арендалау килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү очракларыннан тыш, әгәр анда урнашкан бинага, корылмага, төзелеше тәмамланмаган объектка карата рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турында карар яисә рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү һәм аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул ителгән, күрсәтелгән карарларда билгеләнгән срокларда Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 11 бүлегендә каралган бурычлар үтәлмәгән очракта);<br>10) җир участогында дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект урнашкан һәм әлеге биналарны, корылмаларны, төзелеше тәмамланмаган объектларны сату яки арендага бирү башка аукцион предметы булып тора яисә әлеге бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект сатылмаса яки бу аукционда җир участогы белән бер үк вакытта арендага бирелмәсә (җир участогында сервитут, җәмәгать сервитуты нигезендә урнаштыру рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки РФ Җир кодексының 39.36 статьясы нигезендә урнаштырылган объектлар булган очраклардан тыш);<br>11) җир участогы әйләнештән алынган (федераль закон нигезендә әйләнештән алынган җир участоклары аренда килешүе предметы булырга мөмкин очраклардан тыш);<br>12) җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган (җир участогын резервлау срогыннан артмаган срокка җир участогын арендалау килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү очрагыннан тыш);<br>13) җир участогы, аны үстерү турында килешү төзүгә мөнәсәбәтле төзелгән территория яки аны комплекслы үзләштерү турында килешү төзелгән территория чикләрендә урнашкан;<br>14) җир учатогы расланган территориаль планлаштыру документлары һәм (яки) территорияне планлаштыру документлары нигезендә федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны яки | |

| | | |
|---|---|---|
| | җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән;<br>15) җир участогы Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы яки адреслы инвестицион программа нигезендә бина яки корылманы урнаштыру өчен билгеләнгән;<br>16) җир участогына карата аны бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән;<br>17) җир участогына карата аны бирүне алдан килештерү турында гариза яки җир участогы бирү турында гариза кергән (мондый җир участогын бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карар яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очраклардан тыш);<br>18) җир участогы гомуми файдаланудагы җир участогы булып тора яки гомуми файдаланудагы җирләр, гомуми файдаланудагы территория чикләрендә урнашкан;<br>19) җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алыну (мондый җир участогында урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану сәбәпле, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир участокларыннан тыш);<br>20) гариза бирүче тарафыннан аукционда катнашу өчен кирәкле документлар тапшырылмау яки дөрес булмаган мәгълүматлар тапшырылу;<br>21) аукционда катнашу өчен заявкаларны карап тикшерү датасына задатокның килмәве;<br>22) гариза бирүче турында, гамәлгә куючылар (катнашучылар) турында, гариза бирүченең коллегиаль башкарма органнары әгъзалары турында, гариза бирүченең юридик зат булып торучы бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы затлар турында белешмәләрнең аукционда намуссыз катнашучылар реестрында булуы;<br>23) аукционда катнашуга гаризаның, әлеге Кодекс һәм башка федераль законнар нигезендә, конкрет аукционда катнашучы, җир участогын сатып алучы яки җир кишәрлеген арендага алучы булу хокукына ия булмаган зат тарафыннан бирелүе | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезе, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, муниципаль хезмәтеннән файдалануга гариза бирү – 15 минуттан артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.<br>Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | Эш регламенты |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу, аның чикләрендә хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен дә истә тотып урнаштырыла | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) Башкарма комитет бинасының җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>2) кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>3) мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>1) документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә документлар биргәндә чиратлар;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>3) муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр;<br>4) муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ хезмәткәре гамәлгә ашыра. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәттән электрон рәвештә файдалану тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Әгәр законда муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны электрон рәвештә бирү каралган булса, ул очракта гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru) яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http:// www.gosuslugi.ru) аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:
1) гариза бирүчегә консультация бирү;
2) гаризаларны кабул итү һәм теркәү;
3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;
4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;
5) аукцион үткәрү;
6) җир участогын арендалау килешүе төзү һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша Башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

ҖММИ белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалану өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гаризалар бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалануның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яки вәкаләтле зат, Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны теркәп, Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача гаризалар бирә.

Регламентның 2.5 пункты нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон рәвештәге гаризалар электрон почта аша Башкарма комитетка җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаларны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:
1) гариза бирүченең шәхесен ачыклауны;
2) гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч язуы буенча эш иткәндә);
3) Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерүне;
4) тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен (документларның күчермәләре тиешенчә рәсмиләштерелүне, документларда бозып төзәтүләр, өстәп язулар, сызган сүзләр булмауны) тикшерүне.

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:
1) теркәлгән документлары белән гаризаны (алга таба – гариза) кабул итүне һәм «Электрон документлар әйләнеше» системасы аша гаризаларны теркәүне;
2) гаризаларны, аларга теркәлгән документларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне.

Регламентның 2.8 пункты нигезендә, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гариза бирүчегә гаризаларны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, гариза бирүчегә документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) гаризаларны һәм аларга теркәлгән документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

2) гаризаларны һәм аларга теркәлгән документларны теркәү – гаризалар кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гаризалар һәм аларга теркәлгән документлар яисә гариза бирүчегә кире кайтарылган гаризалар һәм аларга теркәлгән документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаларны һәм аларга теркәлгән документларны карап тикшерә һәм ҖММИ башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризалар теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ башлыгына җибәрелгән гаризалар һәм аларга теркәлгән документлар.

3.3.4. ҖММИ башлыгы гаризаларны, документларны карап тикшерә һәм аларны ҖММИнең җир ресурслары белән идарә итү бүлеге башлыгына (алга таба - ҖММИ бүлеге башлыгы) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризалар һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән гаризалар һәм документлар.

3.3.5. ҖММИ бүлеге башлыгы гаризаларны, документларны карап тикшерә һәм аларны ҖММИнең җир ресурслары белән идарә итү бүлеге белгеченә (алга таба – ҖММИ белгече) җибәрә.

Срок: 1 эш көне.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ белгеченә җибәрелгән гаризалар һәм документлар.

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. ҖММИ белгече гамәлгә ашыра:

1) норматив хокукый базаны исәпкә алып, гаризаларны һәм документларны карап тикшерүне;

2) Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру турындагы запросларны электрон рәвештә формалаштыру һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә җибәрне.

Срок: 1 эш көне.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон рәвештә җибәрелгән ведомствоара запрослар.

3.4.2. Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, сорала торган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле мәгълүмат булмау турында белдерү кәгазьләре (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе) җибәрәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

- Росреестр белгечләренә җибәрелә торган мәгълүматлар буенча, өч эш көненнән артмаган срокта;

- башка тәэмин итүчеләр буенча – федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән очракта, документ яки мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (мәгълүмат) яисә ҖММИ белгеченә җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. ҖММИ белгече, кергән документлар (мәгълүмат) нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен Регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләрнең булуын тикшерә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булган очракта, ҖММИ белгече муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын (алга таба – баш тарту турында хат) әзерли һәм аны килештерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, ҖММИ белгече:

1) аукцион үткәрү турында Башкарма комитет карары проектын (алга таба – карар проекты) әзерләүне гамәлгә ашыра;

2) карар проектын килештерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә;

3) җир участогын булдырырга кирәк булган очракта, ҖММИ хезмәткәрләре җир участогының урнашу схемасын раслау буенча административ регламентта каралган гамәлләрне башкаралар.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар (3 пунктчадан тыш) Регламентның 3.4 пунктында каралган документлар (мәгълүмат) кергәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән карар проекты яки баш тарту турында хат.

3.5.2. ҖММИ бүлеге башлыгы карар проектын яки баш тарту турында хатны карап тикшерә, килештерә һәм килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрелгән карар проекты яки баш тарту турында хат.

3.5.3. ҖММИ башлыгы карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм килештерү өчен Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе (алга таба - АШТһТҮИ) башлыгына җибәрә яки баш тарту турында хатны имзалый һәм, теркәү һәм гариза бирүчегә бирү өчен, ҖММИ белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен АШТһТҮИ башлыгына җибәрелгән карар проекты яисә теркәү һәм гариза бирүчегә бирү өчен ҖММИ белгеченә җибәрелгән хат.

3.5.4. АШТһТҮИ башлыгы карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм Башкарма комитетның Хокук идарәсенә (алга таба – Хокук идарәсе) җибәрә.

Карар проектына карата кимчелекләр булган очракта, АШТһТҮИ башлыгы кимчелекләрне төзәтү өчен карар проектын ҖММИ белгеченә кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен Хокук идарәсенә җибәрелгән карар проекты яисә  карар проектындагы кимчелекләр буенча ҖММИ белгеченә җибәрелгән күрсәтмәләр.

3.5.5. АШТһТҮИ башлыгы тарафыннан карар проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр җибәрелгән очракта, ҖММИ белгече кимчелекләрне төзәтә һәм карар проектын алга таба килештерү өчен АШТһТҮИ  башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән һәм АШТһТҮИ башлыгына җибәрелгән карар проекты.

3.5.6. АШТһТҮИ башлыгы  төзәтелгән карар проектын карап тикшерә, аны килештерә һәм Хокук идарәсе башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: АШТhТҮИ башлыгы тарафыннан килештерелгән, Хокук идарәсе башлыгына җибәрелгән карар проекты.

3.5.7. Хокук идарәсе башлыгы карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Тапшырылган документлар норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, Хокук идарәсе башлыгы карар проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр әзерли һәм әлеге кимчелекләрне төзәтү өчен аны ҖММИ белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты яисә төзәтү өчен ҖММИ белгеченә җибәрелгән карар проектындагы кичелекләргә карата күрсәтмәләр.

3.5.8. Хокук идарәсе башлыгы тарафыннан карар проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр җибәрелгән очракта, ҖММИ белгече кимчелекләрне төзәтә һәм алга таба килештерү өчен, карар проектынХокук идарәсе башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән һәм хокук идарәсе башлыгына җибәрелгән карар проекты.

3.5.9. Хокук идарәсе башлыгы төзәтелгән карар проектын карап тикшерә, аны килештерә һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Хокук идарәсе башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.5.10. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:

1) ахыргы варианттагы карар проектын тикшерә;

2) вазыйфаи затларның кирәкле визалары, Башкарма комитет карарларын (боерыкларын) бирү реестры булуны (булмауны) тикшерә;

3) карар проектын Башкарма комитет бланкында бастыра;

4) имзалау өчен карар проектын Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар карар проекты эш кәгазьләрен алып бру идарәсенә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән карар проекты.

3.5.11. Башкарма комитет Җитәкчесе карар проектын имзалый һәм теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.5.12. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) карар проектын Башкарма комитет карарларын теркәү журналында теркәүне;

2) карарларны бирү реестры нигезендә карарларның күчермәләрен бирүне.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән карар, карарларны бирү реестры нигезендә бирелгән карарларның күчермәләре.

3.5.13. ҖММИ белгече гариза бирүчегә (аның вәкиленә), гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, аукцион үткәрү турында карар имзалану яисә аукцион үткәрүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура күрсәтелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (аның вәкиленә) аукцион үткәрү турында карарның имзалануы турында хәбәр итү.

3.5.14. АШТҺТҮИ белгече, имза куйдырып, аукцион үткәрү турындагы карарны гариза бирүчегә бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, гариза бирүче шәхсән килгән очракта, 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: аукцион үткәрү турында гариза бирүчегә бирелгән карар.

3.6. Аукцион үткәрү

3.6.1. ҖММИ белгече аукцион үткәрү турында карарны аукционны оештыручыга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: аукционны оештыручыга җибәрелгән карар.

3.6.2. Аукционны оештыручы, карарны алгач, муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә, аукцион үткәрү турындагы хәбәрне аукцион үткәрү көненә кадәр утыз көннән дә ким булмаган срокта бастырып чыгаруны тәэмин итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аукционны оештыручының регламентында (нигезләмәдә) билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: аукцион үткәрү турында хәбәрне бастырып чыгару.

3.6.3. Аукционны оештыручы аукцион үткәрә һәм аның нәтиҗәләре буенча аукцион нәтиҗәләре турында ике нөсхәдә беркетмә төзи, бер нөсхәне аукционда җиңүчегә бирә, ә икенчесен ҖММИгә җибәрә. Аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә аукционны оештыручы тарафыннан Россия Федерациясенең рәсми сайтында урнаштырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

беркетмәне аукционда җиңүчегә  бирү - аукцион көнендә;

беркетмәне Россия Федерациясенең рәсми сайтында урнаштыру - әлеге беркетмә имзаланган көннәнбашлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: беркетмәне аукционда җиңүчегә бирү һәм беркетмәне Россия Федерациясенең рәсми сайтында урнаштыру.

3.7. Килешү төзү һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.7.1. ҖММИ белгече, аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәне алгач, җир участогын арендалау килешүе проектын (алга таба - килешү проекты) әзерләүне гамәлгә ашыра һәм килештерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзалау өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән өч нөсхәдәге килешү проекты.

3.7.2. ҖММИ бүлеге башлыгы килешү проектын килештерә һәм килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура килешү проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ бүлеге башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрелгән килешү проекты.

3.7.3. ҖММИ башлыгы килешү проектын килештерә һәм Хокук идарәсенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура килешү проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ башлыгы белән килештерелгән һәм килештерү өчен Хокук идарәсе башлыгына җибәрелгән килешү проекты.

3.7.4. Хокук идарәсе башлыгы килешү проектын карап тикшерә, килештерә һәм имзалау өчен аны Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Тапшырылган документлар норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, Хокук идарәсе башлыгы килешү проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр әзерли һәм әлеге кимчелекләрне төзәтү өчен аны ҖММИ белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаган вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән килешү проекты яисә төзәтү өчен ҖММИ белгеченә җибәрелгән күрсәтмәләр.

3.7.5. Хокук идарәсе башлыгы тарафыннан килешү проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр җибәрелгән очракта, ҖММИ белгече кимчелекләрне төзәтә һәм килешү проектын алга таба килештерү өчен Хокук идарәсе башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура күрсәтмәләр кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән һәм килештерү өчен Хокук идарәсе башлыгына җибәрелгән килешү проекты.

3.7.6. Хокук идарәсе башлыгы төзәтелгән килешү проектын карап тикшерә, аны килештерә һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм килештерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән килешү проекты.

3.7.7. Башкарма комитет Җитәкчесе килешү проектын имзалый һәм теркәү өчен ҖММИгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәү өчен ҖММИгә җибәрелгән килешү проекты.

3.7.8. ҖММИ белгече килешү проектын терки, аукционда җиңүчегә яисә аукционда катнашкан бердәнбер катнашучыга хәбәр итә һәм имзаланган килешү проектының өч нөсхәсен имзалау өчен җибәрә (бирә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) килешү проектын теркәү – 15 минут эчендә;

2) аукционда җиңүчегә яисә аукционда катнашкан бердәнбер катнашучыга хәбәр итү;

3) килешү проектын бирү - 15 минут эчендә, чират тәртибендә, гариза бирүче килгән көнне яисә почта аша хат белән җибәрә - Регламентның 3.7.7 пунктында каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: аукционда җиңүчегә яисә аукционда катнашкан бердәнбер катнашучыга җибәрелгән (бирелгән) килешү проекты.

3.7.9. Аукционда җиңүче яисә аукционда катнашкан бердәнбер катнашучы килешү проектының өч нөсхәсен имзалый һәм ҖММИгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аукционда катнашучыга килешү проекты җибәрелгән көннән башлап утыз календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм ҖММИгә җибәрелгән килешү.

3.8. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү

3.8.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.8.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.3. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮдән документлар кергәндә, процедуралар Регламентның 3.3 – 3.7 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.9. Техник хаталарны төзәтү.

3.9.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә түбәндәгеләрне тапшыра: техник хатаны төзәтү турында гариза (3 нче кушымта), гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ, техник хаталар булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар. Муниципаль хезмәт

күрсәтү нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып), яисә бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки КФҮ аша бирелә.

3.9.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итүне, теркәүне гамәлгә ашыра һәм аларны Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза.

3.9.3. Техник хатаны төзәтү турында гариза кергәндә, муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып исәпләнгән документка төзәтмәләр кертү максатында, әлеге Регламентның 3.3.3, 3.3.4 һәм 3.5 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла. ҖММИ белгече төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә, төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып һәм имза куйдырып, техник хата булган документны (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки техник хаталы документның нөсхәсен ҖММИгә тапшырганда документны алу мөмкинлеге турындагы хатны гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура җибәрелгән хата турында теләсә кайсы кызыксынган заттан гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, Башкарма комитет вазыйфаи затларының карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш кәгазьләрен алып баруны билгеләнгән тәртиптә үткәрелгән тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлүен контроль тикшерүләрне билгеләнгән тәртиптә үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр вакытында муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә эш итүләрне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатында Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында рәсми язулар бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген саклауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы Башкарма комитет вазыйфаи затларының исемлеге Башкарма комитетның структур бүлекчәләре турындагы нигезнамәләр һәм вазыйфаи инструкцияләр нигезендә билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләренең үз вакытында каралмавы өчен җаваплы.

ҖММИ башлыгы Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ процедураларның үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул иткән (гамәлгә ашырган) карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5 Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә – Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләре буенча – КФҮгә яисә КФҮне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1. статьясында күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш,

муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), КФҮ, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) рәсми сайтыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап 15 эш көне эчендә. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш.

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

5.6. Шикаять аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, КФҮ яисә 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 бүлегендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм

муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктта күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, кимчелекне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.

Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.11. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Муниципаль милектәге җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУга
____________________________________________________
(физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары, ИНН)
____________________________________________________
(юридик затлар өчен - исеме, урнашу урыны, оештыру-хокукый формасы, Бердәм дәүләт юридик затлар реестрында, Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу органында дәүләт теркәве турында мәгълүматлар)
____________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү өчен
җир участогы булдыру турында
гариза

Сездән җир участогы булдыруны ____________________________________________
________________________________________________________________
(җир участогыннан файдалану максаты күрсәтелә)
һәм аны аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирүне сорыйм.
Җир участогы түбәндәге характеристикаларга ия:
мәйданы ____________ кв. м,
кадастр номеры 16:___:__________:___,
рөхсәт ителгән файдалану төре ______________________________________________,
җирләрнең категориясе ____________________________________________________,
урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре,______________________
______________________ районы, урамы, _____ йорт.
Гаризага түбәндәге документлар (сканерланган күчермәләр) теркәлә:
- физик затлар өчен:
1) шәхесне раслаучы документ күчермәсе (граждан өчен);
2) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);
- юридик затлар өчен:
вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә).

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә

карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның сканерланган күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.

_______________ __________________ (________________________________________)
(дата) (имза) (Ф. И. А.и.)

Муниципаль милектәге җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУга
______________________________________________________
(физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары, ИНН)
______________________________________________________
(юридик затлар өчен - исеме, урнашу урыны, оештыру-хокукый формасы, Бердәм дәүләт юридик затлар реестрында, Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу органында дәүләт теркәве турында мәгълүматлар)
______________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү өчен
җир участогы бирү турында
гариза

Сездән җир участогы бирүегезне сорыйм _______________________________________
______________________________________________________________________________
(җир участогыннан файдалану максаты күрсәтелә)
аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага.
Җир участогы түбәндәге характеристикаларга ия:
мәйданы ___________ кв. м,
кадастр номеры 16:___:_________:___,
рөхсәт ителгән файдалану төре _______________________________________________,
җирләрнең категориясе _______________________________________________________,
урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, ____________________
_____________________ районы, урамы, _____ йорт.
Гаризага түбәндәге документлар (сканерланган күчермәләр) теркәлә:
- физик затлар өчен:
1) шәхесне раслаучы документ күчермәсе (граждан өчен);
2) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);
- юридик затлар өчен:
вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә).

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт

күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.


Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның сканерланган күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.


Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.


______________ _________________ (_____________________________________)


Муниципаль милектәге җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

## Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы




ҖММИ белгече карар яки баш тарту турында хат проекты әзерли.
Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, ҖММИ белгече:
- аукцион үткәрү турында Башкарма комитет карары проектын (алга таба - карар проекты) әзерләүне гамәлгә ашыра;
- карар проектын ҖММИ бүлеге башлыгына килештерүгә җибәрә;
- җир участогын булдырырыга кирәк булган очракта, ҖММИ хезмәткәрләре җир участогының урнашу схемасын раслау буенча административ регламентта каралган гамәлләрны башкаралар
Килештерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән карар проекты
Килештерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән баш тарту турында хат проекты
ҖММИ бүлеге башлыгы карар проектын килештерә һәм килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрә
ҖММИ бүлеге башлыгы баш тарту турында хат проектын килештерә һәм имзалау өчен ҖММИ башлыгына җибәрә
ҖММИ башлыгы карар проектын килештерә һәм килештерү өчен АШТһТҮИ башлыгына җибәрә
ҖММИ башлыгы баш тарту турында хатны имзалый, теркәү һәм гариза бирүчегә бирү өчен ҖММИ белгеченә җибәрә
АШТһТҮИ башлыгы карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм килештерү өчен Хокук идарәсе башлыгына җибәрә яисә кимчелекләргә карата күрсәтмәләр әзерли һәм карар проектын төзәтү өчен ҖММИ белгеченә кире кайтара
Теркәү һәм гариза бирүчегә бирү өчен ҖММИ белгеченә җибәрелгән баш тарту турында хат
ҖММИ белгече карар проектындагы кимчелекләрне төзәтә һәм АШТһТҮИгә җибәрә
ҖММИ белгече баш тарту турында хатны терки һәм аны гариза бирүчегә җибәрә
Имзаланган һәм гариза бирүчегә җибәрелгән баш тарту турында хат
Килештерелгән һәм килештерү өчен Хокук идарәсе башлыгына җибәрелгән карар проекты
Хокук идарәсе башлыгы карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә яисә кимчелекләргә карата күрсәтмәләр әзерли һәм төзәтү өчен карар проектын ҖММИ белгеченә кире кайтара
Килештерелгән һәм Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты
ҖММИ белгече карар проектына карата Хокук идарәсе башлыгы күрсәткән кимчелекләрне төзәтә һәм Хокук идарәсе башлыгына җибәрә
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:
- ахыргы варианттагы карар проектын тикшерә;
- вазыйфаи затларның кирәкле визалары, Башкарма комитет карарларын (боерыкларын) бирү өчен реестр булуны (булмауны) тикшерә;
- карар проектын Башкарма комитет бланкында бастыра;
- имзалау өчен карар проектын Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә
Имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән карар проекты


Башкарма комитет Җитәкчесе карар проектын имзалый һәм теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә
Имзаланган һәм теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:
- карар проектын Башкарма комитет карарларын теркәү журналында теркәүне;
- карарларны бирү реестры нигезендә карарларның күчермәләрен бирүне.
Карарлар бирү реестры нигезендә җибәрелгән аукцион үткәрү турында Башкарма комитет карары (алга таба - карар)
ҖММИ белгече карарны аукционны оештыручыга җибәрә
Аукционны оештыручыга җибәрелгән карар
Аукционны оештыручы аукцион үткәрү турында хәбәрне бастырып чыгаруны тәэмин итә
Бастырып чыгарылган хәбәр
Аукционны оештыручы аукцион үткәрә һәм аның нәтиҗәләре буенча аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә рәсмиләштерә
Аукцион нәтиҗәләре турында рәсмиләштерелгән беркетмә
Аукционны оештыручы аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәнең бер нөсхәсен аукционда җиңүчегә бирә, ә икенчесен ҖММИгә җибәрә. Аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмә аукционны оештыручы тарафыннан РФ рәсми сайтында урнаштырыла
Бер нөсхәсе аукционда җиңүчегә бирелгән, икенче нөсхәсе ҖММИгә җибәрелгән аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә. РФ рәсми сайтында урнаштырылган аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә
ҖММИ белгече, аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәне алгач, өч нөсхәдә килешү проектын әзерли һәм килештерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә
Килештерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән килешү проекты
ҖММИ бүлеге башлыгы килешү проектын килештерә һәм килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрә
Килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрелгән килешү проекты
ҖММИ башлыгы килешү проектын килештерә һәм килештерү өчен Хокук идарәсе башлыгына җибәрә
Килештерү өчен Хокук идарәсе башлыгына җибәрелгән килешү проекты


Хокук идарәсе башлыгы килешү проектын карап тикшерә, килештерә һәм имзалау өчен аны Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә яисә кимчелекләргә карата күрсәтмәләр әзерли һәм ҖММИ белгеченә җибәрә
Килештерелгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән килешү проекты
ҖММИ белгече Хокук идарәсе башлыгы күрсәткән кимчелекләрне төзәтә һәм Хокук идарәсе башлыгына җибәрә
Башкарма комитет Җитәкчесе килешү проектын имзалый һәм теркәү өчен ҖММИгә җибәрә
Имзаланган һәм ҖММИгә җибәрелгән килешү проекты
ҖММИ белгече килешүне терки, аукционда җиңүчегә яисә аукционда катнашкан бердәнбер катнашучыга хәбәр итә һәм имзаланган килешү проектының өч нөсхәсен имзалау өчен җибәрә (бирә)
Аукционда җиңүчегә яисә аукционда катнашкан бердәнбер катнашучыга җибәрелгән (бирелгән) килешү проекты
Аукционда җиңүче яисә аукционда катнашкан бердәнбер катнашучы килешү проектының өч нөсхәсен имзалый һәм ҖММИгә җибәрә
Имзаланган һәм ҖММИгә җибәрелгән килешү
ҖММИ бүлеге белгече, килешүне теркәп, теркәү турында гаризаны хокукларны теркәү органына җибәрә
Килешүне Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәү

Муниципаль милектәге җир участогын аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта (белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | kancel.chelny@tatar.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы | 30-55-54 | uzioip@yandex.ru |
| Башкарма комитет җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең аренда мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге башлыгы | 30-55-54 | uzioip@yandex.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече | 30-55-54 | uzioip@yandex.ru |